## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге Атлас торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

24 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2022 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2023 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Атлас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1200,00 (бер мең ике йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 600,00 (алты йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итәргә;
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудырырга;
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудырырга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештырырга;
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештырырга,
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештырырга;
- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирергә;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашырга;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотарга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, юынтык суны чыгаруны оештырырга;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештырырга?

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 29 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 21, бу 72 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 21 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең Атлас торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Атлас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1200,00 (бер мең ике йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 600,00 (алты йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыруга;
- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга;
- Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирүгә;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруга;
- Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, юынтык суны чыгаруны оештыруга;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Тойгелде авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Д.М.